

# МӘКТӘП ДУЛКЫНЫНДА

**_Күәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы_** _№2 Декабрь 2022 ел_

## Укучыларыбыз иҗаты



### Яңа ел җитә дуслар!

Алланып таңнарның алына,
Нур булып кешелек таңына,
Җыр булып үрелеп күңелгә,
Кил безгә, Яңа ел, кил безгә!

Кояшлы көннәрнең җылысын,
Бәхетнең, шатлыкның олысын
Күтәреп көннәрнең иңенә,
Рәхим ит Туган ил түренә!

### Кар ява урамда...

Салмак кына ,вак кына
Күзгә тунып ,салып кигән
Ак койрыклы куян да.
Карлар ява урамда...
Балыклар боек кала,
Боз өстен каплый юрган
Мартка кадәр салмаска!
Карлар ява урамда...
Аю качты өненә,
Тиенкәйләр йөгерә
Туңмаска дип урманда.
Карлар ява урамда...
Керпе качты тиз генә
Зәмһәер салкын бүген дә
Кагылмасын үзенә.
Карлар ява урамда...
Тын гына,матур гына,
Тиздән җитәр яңа ел
Төренде дөнья карга.

*Хафизов Кәрим ,7 сыйныф*



**Кыш**

Салкын җилләре исеп
Килде салкын кыш,ай-яй!
Кышны сагынган балалар
Тәгәрәтте кар бабай.

*Юсупова Динә,1сыйныф*



**Укытучым**

Укытучы бик җаваплы
Бик авыр һөнәр җирдә
Шуңа класс җитәкчемә
Рәхмәт әйтәсем килә.
Рәхмәт Сезгә, бик гадел Сез,
Эчкерсез зур йөрәкле.
Шигырем аша җиткерәм
Сезгә олы хөрмәтне.

*Юсупов Рөстәм,3сыйныф*

Бүгенге санда:

- Укучылар иҗаты
  - * Яңа ел җитә
  - *Йөрәкләрдә күңел тынычлыгы
  - *Укытучы-икенче әни!
  - *Укучы фикере
- Без –спортта!
- Яңалыклар.



### Минем яраткан беренче укытучым!

Укытучы! Әлеге сүзне ишетүгә күбебезнең күз алдына нәни кулларыбыздан тотып язарга өйрәткән беренче укытучыбыз килеп баса.Һәр кешенең дә “Минә ул - чын укытучы”, - диярлек остазы бар. Еллар узган саен сагынып искә аласың, гомер буе рәхмәт укыйсың аңа.

Минем онытылмас укытучым - Фазылҗанова Рузилә Илдус кызы. Минем аның турында язасым килде, чөнки ул минем әниемне, апаемны һәм туганарымны да укыткан. Гомумән, Дусым авылында Рузилә апа укыткан бернечә буен яши, аны хөрмәт итмәгән кеше юктыр. Укытучы апам язмышы белән якыннанрак танышу өчен көзге матур кичтә мин аларга юл тоттым. Бу очрашуыбызда ул минем сорауларыма җавап бирде.

Рузилә Илдус кызы 1964 елның 29 февралендә районыбызның иң гүзәл төбәкләренең берсе Күәм авылында дөньяга килә. Мәктәпкәчә Күәм балалар бакчасында тәрбияләнеп, 1971 елның 1 сентябрендә Күәм сигезьеллык мәктәбенең 1 сыйныфына укырга керә. “Олы йөрәкле укытучым Гөлсинә апа Шәрипова безгә - 27 укучыга ныклы белем һәм тәрбия бирде. Сабыр, тыйнак, укытучым миндә үз һөнәренә мәхәббәт уятты. 4 сыйныфтан сыйныф җитәкчем Нурания апа Батталова булды. Укытучыларым Роза апа Зарипова, Вәсилә апа Кәримова, Илсия апа Хабибуллина, Земфира апа Бургановалар мина үрнәк булдылар”, - дип үткәннәрне сагынып искә алды. Ул 1979 елда мәктәпне тәмамлаганнан соң, киләчәген мөгаллимлек һөнәре белән бәйләргә теләп, Арча педагогия училищесына юл тота. Анда 4 ел укып, башлангыч сыйныфларда укыту методикасыннан тирән белем туплап, кулына диплом ала һәм хезмәт юлын тәүге тапкыр 1983 елда Дусым башлангыч мәктәбендә башлап җибәрә .

“Тормыш йомгагымны сүтә-сүтә, утыз сигез ел үзем сайлаган һөнәремне башкардым. Хезмәтемне бик яраттым. Укучыларымның күңелен аңларга тырышып, кирәк чакта аларга ярдәм кулы сузып эшләдем”, - ди ул тыйнак кына. Баштагы елларда бер ук вакытта 3 классны бергә укыта. Берүзегез ничек түздегез, дип соравыма Рузилә апа, укучыларының белемгә омтылучан тәртипле булуларын әйтте. Әйе, без дә Рузилә апа белән балачакта һәр бәйрәмдә авыл клубында концертлар куя идек. Әкиятләр сәхнәләштерергә бик теләп катнаша идек.

Рузилә апа укучыларын яратып, һөнәрен намус белән башкарып, 1994 елда “Өлкән укытучы”, 2003 елда “ I категорияле укытучы” исеменә лаек була. “Тормышымның бер минуты да, ягъни бер мизгеле дә шул мәктәп тормышыннан башка үтмәде. Кайда гына булсам да, нәрсә генә эшләсәм дә, күңелгә һаман да шул шау – шулы мәктәп тормышы, гөр килеп торган укучылар килә. Аларның һәркайсын барлыйм. Уңышларына куанам”, - дип сүзен дәвам итә, ул үзенең башкарган хезмәтеннән бик канәгать булып яши.

Бүген ул лаеклы ялда.Улы һәм кызы, оныкларына куанып яши. Дусым авылы халкына дини хезмәт күрсәткән тормыш иптәше Равил абыйга да зур таяныч ул. Беренче укытучыма сәламәтлек, һәрвакыт шулай сабыр олы йөрәкле булуын телим.

*Борһанова Айсинә , 9 сыйныф*

## Яхшы эш- күңелне җылыта.



Ямьле, матур көн иде. Без дуслар белән мәктәп лагерена килдек. Уйнадык, рәсем ясадык. Аннан соң безгә ЮХИДИ хезмәткәрләре юл йөрү дәресләре бунча конкурс уткәрергә килделәр. Мин дусларым белән конкурста катнаштым. Бүләкләр алдык, шулай вакыт та үтте. ЮХИДИ хезмәткәрләренең китәр вакыты җитте Шул вакыт мәктәп тирәсендә үсеп утырган каеннарның берсеннән бер кошчыкның бик каты итеп ярдәм сорап кычкырганы ишетелде. Без ярдәмгә ашыктык, кошчыкны эзли башладык. Озак эзләргә туры килмәде, агачларда урнаштырылган сыерчык ояларының берсендә кечкенә генә кош баласының кысылып калганын күреп алдык. Ләкин коткару өчен баскыч кирәк. Нишләргә? Конкурс үткәрергә килгән кешеләрнең үзләре белән баскыч булган, шуны эшкә җиктек. Хезмәткәрләрнең берсе баскычтан менеп кошчыкка ярдәм итте. Сандугач баласы рәхмәт әйтеп уйнаклап очып китте. Ә безнең күңелгә рәхәт иде.

***Назмиева Алинә, 6 сыйныф***

### Әнием

Әниемне бик яратам,
Акыллы, бик уңган ул.
Йөзеннән нур балкып тора,
Үзе тырыш, булган ул!
Бергә дәрес хәзерлибез
Бергә китап укыйбыз.
Минем, аның теләкләрен
Ярты сүздән аңлыйбыз.
Кайгыда да, шатлыкта да
Серебез уртак безнең.
Елмаюы белән җылыта
Көннәре салкын көзнең.
Тиздән әниләр бәйрәме!
Бик күркәм, матур бәйрәм.
Бүләк итәм, сина әнием.
Чәчәкләр бәйләм-бәйләм.

***Шакиров Раяз ,4 сыйныф***

### Әни, әнием

Минем әни шундый уңган,
Тәмле ризык пешерә.
Чәк-чәк, пирог, тортлар
Барысы да тәмле була
Мин әнигә булышам,
Кибетләргә ашыгам
Әниемнең кызы юк бит,
Улы бар бер дигән!
Мин әнине яратам,
Чәчәкләр дә үстерешәм
Чөнки мин әниемне
Яратам бит, яратам!

***Фазуллин Раяз 4 сыйныф***

### Баян

Баян ул – клавишлы (төймәле) музыка уен коралы. Ул 3 яки 5 рәтле була.

Минем дә баянда уйнарга теләгем зур булды һәм мин баян дәресләренә йөри башладым. Баянда уйнарга безне Ранис абый өйрәтә. Әгәр теләгегез булса, сез дә клубка килегез. Ранис абый сезне дә өйрәтер.

***Хабибуллин Эмиль, 2 сыйныф***

### Әнием!

Әни – җирдә иң газиз, якын кеше. Ул сине тудырган, көйләп бишектә тирбәткән, синең беренче елмаюыңны, беренче әйткән сүзләреңне ишетеп сөенгән, тәпи атлап китүеңне күреп шатланган. Ул безне туган телебезне яратырга өйрәткән. Без үзебезнең тормышыбызны алардан башка күз алдына да китерә алмыйбыз. Алар – безнең дөньябызның яме, шатлыгы.

Һәркемгә үз әнисе дөньядагы иң кадерле кеше булган кебек, миңа да үз әнием бик кадерле. Барлык балаларныкы кебек, минем дә телем "әннә", "әни" сүзе белән ачылган. Әнием минем бик сабыр, тыйнак кеше. Әниемнең исеме Эльмира. Ул Әтнә урта мәктәбендә пешекче булып эшли. Әле ул бик уңган да. Нинди генә эш эшләми әни куллары! Тәмле итеп ашарга да пешерә, безне дә тәрбияли.

Әниемнең йомшак куллары, ягымлы тавышы миңа шатлык китерә. Мин әниемә кулымнан килгәнчә булышырга, аны борчымаска тырышам. Мин мәктәптән кайтуга, без аның белән тәмләп чәй эчәбез, серләребез белән уртаклашабыз. Ял көннәрендә саф һавада йөрергә яратабыз. Әнием мине һәр кичне назлап йоклата, ә иртән "кызым" диеп сөеп уята. Нинди зур бәхет! Ярый әле, әнием, янәшәмдә син бар! Әнием, мин сине бик яратам!

***Шигапова Диляра, 4 сыйныф***

### *5 сыйныф укучыларыннан башваткыч*

### *Яшеренгән кош исемнәрен эзләп тап*



| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| п | е | ч | ы | к | ч | е | н | к |
| н | с | к | п | ү | р | к | а | ы |
| ә | к | ы | ч | г | ә | г | р | ч |
| т | у | к | р | а | н | а | с | р |
| с | а | е | с | к | а | н | ы | е |

## Әтием- горурлыгым!

Минем әтием Калимуллин Раузит Рәйханович, ул 1982 елда Балтач районы Салавыч авылында туа. Кечкенәдән бик кызу, җитез бала булып үскән. Кечкенәдән ук атлар яраткан. Атларны яратып, үзенә ат чабышларында катнашам дип максат куйган.Ул көне-төне атларны тәрбияләгән, атлар турында кубрәк белергә теләгән, атта чабырга өйрәнгән. Ә инде 15 яшендә әтием беренче тапкыр ат чабышында катнаша. Шул ат чабышында 19 ат арасында әтием иң соңгысы булып килгән... Ләкин әтиемнең тырышулары юкка чыкмый. Шушы ат чабышында Мәскәүдән килгән бер абый булган, ул әтием янына килеп исәнләшкән, «Син иң соңгы булып килсәң дә, минем соңгы атка, бу егеткә бүләк бирәсем килә», дип иң зур бүләк телевизор бүләк итә. Ә инде шул ат чабышыннан соң, әтием ел саен беренче урын алып барган, аның үзенең атлары да булган. Атларны яратуы, әтинең уңышлары турында район газеталарына язып чыгарганнар. 2008 елга кадәр эти бәйгеләрдә катнашып беренче урынны беркемгә бирми. Бүгенге көндә дә яшүсмер вакытлары турында, ярыш бәйгеләр турында безгә сөйли. Балтачка кунакка кайткач, безгә матур урыннарны, су буйларын, сабантуй мәйданнарын күрсәтә. Хәзерге көндә ул Казанда мебель цехында эшли. Анда төрле матур, диваннар һәм кресло, урындыклар эшлиләр. Мин әтием белән бик горурланам. Ул гаиләбезнең терәге. Ул безне ярата, кайгыртып тора, максатына ирешә торган көчле ир егет. Без әтиебезне яратабыз һәм хөрмәт итәбез.

***Калимуллина Гөлия, 8 сыйныф***

## Укучы фикере

### *Әдәпле бала нинди була?*

Минем уйлавымча , әдәпле бала –ул әти-әнисенең сүзен тыңлый, яхшы укый, зурларга һәрвакыт булыша торган бала. Әдәпле бала мәктәптә дә, урамда да, өйдә дә әдәпле булырга тиеш. Андый бала үскәч тә, рәхәт, матур тормышта яши. Аны бөтен кеше хөрмәт итә. Андый бала начар юлга басмас. Әти-әнисенең битенә кызыллык китермәс. Минем әнием безгә һәрвакыт :"Әдәп базарда сатылмый" ,–дип әйтә. Чыннан да, әнием дөрес әйтә. Әдәпле булырга кеше өйрәнергә тиеш. Әдәпсезлекләрне күреп тә, әдәплелеккә өйрәнергә мөмкин.

***Халитова Ильвинә ,5 сыйныф***

### Без- спортта



Хоккей мәйданчыгында хоккей уеннары башланып китте.18декабрь көнне Күәм авылы бозында өч команда очрашты. Анда Бәрәскә, Мәңгәр һәм боз хуҗалары Күәм командалары катнашты. Бу ярыш, авылдашыбыз Зарипов Илгизәр исемендәге турнир буларак уздырылды. Ул безнең авылыбызда уза торган традицион бәйге. Һава торышы безгә комачауламады, безнең команда бик матур уен күрсәтте. Мәктәп командасы җиңү яулады. Классташыбыз Бариев Фәнил капкада торучы. Ул бик тырыш, әзерлекле булып шайбаларны үткәрмәде. Барлык команда егетләре тырышып уйнадылар. Җиңүчеләр буларак, безнең командага кубок һәм медальләр тапшырылды. Тренерыбыз Зарипов Булат һәм безнең команда уен нәтиҗәләре белән канәгать.

***Закиров Илхам, 8 кл укучысы***

**Яңалыклар**

- Бөек математик Н.Лобачевскийның 1 декабрьдә туган коне. Ул 1792 елда туган.
- Балалар язучысы Резеда Шәриповага 5 декабрьдә 60 яшь тулды.




**Озак еллар мәктәбебездә химия дәресләре укыткан укытучыбыз Ләйсән Фәргать кызының декабрьдә туган коне -юбилее. Сезгә эшегездә уңышлар, сәламәтлек, гаиләгездә тынычлык телибез!**